МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 179/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 10 » 10 2017

Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган капиталь төзелеш

объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең дөрес булу-булмавына тикшерү уздыру тәртибе турында» 2009 елның 18 маендагы 427 номерлы, «Проект документациясенең икътисадый нәтиҗәлелек критерийлары турында» 2016 елның 12 ноябрендәге 1159 номерлы, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 427 номерлы карары белән расланган Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 процентган артык булган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең дөрес булу-булмавына тикшерү уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 23 гыйнварындагы 51 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 карары нигезендә боерык бирәм:

1. Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 процентган артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба - дәүләт хезмәте) административ регламентын расларга.

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче итеп «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесен билгеләргә.

3. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң 10 эш көне эчендә аның Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы

министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 10.10.2017 № 179/о боерыгы белән расланды

**Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 процентнан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 процентнан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Административ регламент) финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 процентнан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) административ процедураларның вакытларын һәм эзлеклелеген, вазыйфаи затларның үзара хезмәттәшлек итү тәртибен дә билгели.

1.1.1. Дәүләт хезмәте капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау объектларына карата гамәлгә ашырыла, әгәр дә мондый капиталь ремонт

түбәндәгеләрне үз эченә алса:

а) барлык төр төзелеш конструкцияләрен алмаштыру һәм (яисә) торгызу (терәк булып торучы төзелеш конструкцияләреннән тыш) яисә барлык төзелеш конструкцияләрен алмаштыру һәм (яисә) торгызу (терәк булып торучы төзелеш конструкцияләреннән тыш), – тулаем алганда терәк булып торучы төзелеш конструкцияләренең алмаштырыла торган аерым элементларын аналогик яисә мондый конструкцияләрнең күрсәткечләрен яхшырта торган башка элементларга алмаштыру һәм (яисә) күрсәтелгән элементларны торгызу;

б) инженер-техник тәэминат системаларының барлык төрләрен яисә инженер-техник тәэминат челтәрләренең барлык төрләрен алмаштыру һәм (яисә) торгызу;

в) линияле объектның, мондый объектның классын, категориясен һәм (яисә) функцияләве буенча билгеләнгән беренчел күрсәткечләрен үзгәртүгә китереп чыгармый торган һәм бу вакытта мондый объектны аерып чыгару полосасы һәм (яисә) саклык зонасы чикләрен үзгәртү таләп ителми торган параметрларын үзгәртү.

1.1.2. Дәүләт хезмәте капиталь төзелеш объектларына карата түбәндәгеләргә бәйсез рәвештә гамәлгә ашырыла:

төзелешкә рөхсәт алу зарурлыгына;

проект документациясен әзерләү зарурлыгына;

проект документациясенә һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының зарурлыгына.

1.1.3. Капиталь ремонтка әлеге Регламентның 1.1.1 пунктчасында күрсәтелгән эшләр кертелмәгән очракта, «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенә капиталь төзелеш объектларының капиталь ремонты буенча смета бәясенә тикшер уздыру өчен документлар тапшыру турында карар инициатив тәртиптә кабул ителә:

федераль бюджет акчасын төп бүлүче җитәкчесе тарафыннан (бюджет йөкләмәләре лимитларын бүлеп бирүгә билгеләнгән тәртиптә җитәкче тарафыннан вәкаләт бирелгән җитәкче урынбасары яисә вазыйфаи зат тарафыннан), – федераль мөлкәт объектларына карата, Россия Федерациясе субъектының бюджет акчаларын баш бүлүче җитәкчесе тарафыннан, – Россия Федерациясе субъектларының дәүләт мөлкәте объектларына карата, җирле бюджет акчаларын баш бүлүче җитәкчесе тарафыннан, – муниципаль мөлкәт объектларына карата;

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан төзелгән юридик зат җитәкчесе, устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесе тарафыннан, –мондый юридик затның капиталь ремонты Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларындагы акчаны җәлеп итмичә гамәлгә ашырыла торган объектларына карата;

дәүләт учреждениесе яисә муниципаль учреждение, дәүләт унитар предприятиесе яисә муниципаль унитар предприятие булып тормаган юридик зат җитәкчесе тарафыннан, – мондый юридик затның капиталь ремонты Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларындагы акчаларны җәлеп итеп

финанслана торган объектларына карата.

1.1.4. Дәүләт хезмәте мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләрнең смета бәясенә карата гамәлгә ашырыла, әгәр мондый эшләрне уздыру мәдәни мирас объектларының конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагылса.

1.2. Дәүләт хемәте күрсәтелә торган затлар: дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче (алга таба – Мөрәҗәгать итүче) төзүче, техник заказчы яисә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар. Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышанычнамә яисә үзенең шәхесен таныклаучы документлар нигезендә чыгыш ясый.

1.3. Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе) тарафыннан күрсәтелә.

1.4. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе урнашкан урыны, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат:

Юридик адрес: 420073, Россия, ТР, Казан ш., Шуртыгин ур., 22.

Урнашу урыны: 420054, Россия, ТР, Казан ш., Габдулла Тукай ур., 125.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең элемтә телефоннары:

Казан шәһәре коды: 8 (843);

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе җитәкчесе: 8 (843) 272-04-94;

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе җитәкчесе урынбасары:8 (843) 520-70-50 (өстәмә 401);

техник хезмәт җитәкчесе: 272-65-14 (өстәмә 209);

экспертиза хезмәте җитәкчесе: 241-02-19 (өстәмә 204);

проект-смета документларын кабул итү бүлеге: 272-56-84 (өстәмә 230);

бәяләмәләр белән эшләү һәм аларны бирү бүлеге: 272-65-14 (өстәмә 213);

бухгалтерлык исәбе, хисаплылык һәм финанс бүлеге: 272-65-60 (өстәмә 248);

кадрлар бүлеге: 241-02-14 (өст. 241).

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең электрон почта адресы: expertiza-rt@tatar.ru к

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе турында кирәкле барча мәгълүмат Интернет-сайтларда бар:

expert.kgts.ru

gosekspertiza-rt.ru

госэкспертиза-рт.рф

gosekspertiza.tatarstan.ru

Гаризаларны һәм бүтән документларны дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кабул итү һәм бәяләмәләр бирү вакыты:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе – 9.00 - 18.00;

җомга – 08.00 – 15.45;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре,

төшке тәнәфес: 12.30-13.15.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе бинасына керү кертү кәгазе һәм (яисә) шәхес таныклаучы документ буенча гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4, 1.5, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11 и 5.1 пунктларында булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгеләрдә урнаштырыла:

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatar.ru);

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе сайтында (http://www.gosekspertiza.tatarstan.ru);

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә телдән яисә язмача рәвештә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә».

1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документациясенә һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен оештыру һәм күрсәтү тәртибе турында» 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документациясенә һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм уздыру турында нигезләмә (РФ Законнар җыентыгы, 2007, № 11, 1336 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документациясенең бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары белән расланган Проект документациясенең бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында нигезләмә (РФ Законнар җыентыгы, 2008, № 8, 744 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан акчалар, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль

берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру турында» 2009 елның 18 маендагы 427 номерлы карары белән расланган Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан акчалар, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру турында нигезләмә (алга таба – РФ Нигезләмәсе) (РФ Законнар җыентыгы, 2009, № 21, 2576 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы турында» 2010 елның 8 сентябрендәге 697 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 38, 4823 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавын тикшерү турында бәяләмә рәвешен һәм капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавын тикшерү турында бәяләмәне рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2017 елның 29 мартындагы 655/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 29 мартындагы 655/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 15.05.2017);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздыру һәм капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавын тикшерү өчен тапшырыла торган электрон документлар рәвешенә таләпләр раслау турында» 2017 елның 12 маендагы 783/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 12 маендагы 783/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 25.08.2017);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт

хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 елның 07 августындагы 674 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2012, № 59, 2041 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесен төзү турында» 2015 елның 20 февралендәге 102 номерлы карары (алга таба – 2015 елның 20 февралендәге 102 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, №17, 0593 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (шушы Регламентның 3 нче кушымтасы).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы | Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру | РФ Нигезләмәсенең 1 п. |
| 2.2. Хезмәтне турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе | РФ Нигезләмәсенең 4 п.<br>102 номерлы ТР МК карары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булып капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булуы турында (уңай бәяләмә) яисә төгәл булмавы турында (тискәре бәяләмә) бәяләмә тора. | РФ Нигезләмәсенең 24 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә ярдәм күрсәтүче | Тапшырылган документларның тупланышын тикшерү алар килгән датадан соң 3 эш көне эчендә уздырыла.<br>Смета бәясенең төгәл булуын тикшерү килешүдә | РФ Нигезләмәсенең 15, 19 - 20, 20(1) пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | каралган чорда уздырыла, ул 30 эш көненнән артык була алмый.<br>Смета бәясенә тикшерү уздырганда смета документациясенә үзгәрешләр кертү килешүдә каралган чорларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырылырга мөмкин.<br>Бу вакытта смета бәясенә тикшерү уздыру килешү яисә аңа өстәмә килешү нигезендә озайтылырга мөмкин, әмма ләкин 30 эш көненнән дә артыграк түгел.<br>Әгәр смета бәясен тикшерү бер үк вакытта проект документациясенә һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздырып яисә проект документациясе модификациясе турында бәяләмә әзерләп башкарылса, мондый тикшерү дәүләт экспертизасын уздыру яисә проект документациясе модификациясе турында бәяләмә әзерләү чоры кысаларында гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган<br>Әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының капиталь ремонты буенча смета бәясенә тикшерү уздыру чоры Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары торучы вазыйфаи затының тиешле йөкләмәсе (карары) булган очракта кыскартылырга мөмкин, ләкин кимендә 10 эш көненә кадәр | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган | 1. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, шулай ук гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын капиталь ремонтлауның смета бәясенә тикшерү уздыру өчен капиталь төзелеш объектын төзүче (техник заказчы) яисә аның исеменнән эш йөртүче зат (алга таба – мөрәҗәгать | РФ Нигезләм |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | итүче) түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а) смета бәясенә тикшерү уздыру турында гариза (3 нче кушымта), аңа мөрәҗәгать итүче кул куя һәм анда түбәндәгеләр күрсәтелә:<br>проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашырган һәм инженерия эзләнүләрен башкарган затлар турында идентификация белешмәләре (фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен таныклаучы документының реквизитлары, шәхси эшкуарның яшәгән урыны буенча почта адресы, юридик затның тулысынча аталышы һәм урнашкан урыны);<br>үзенә карата проект документациясе смета бәясен тикшерү өчен тапшырылган капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре (төзелеше күздә тотылган объектның аталышы, капиталь төзелеш объектының почта (төзелү) адресы, капиталь төзелеш объектының төп техник-икътисадый сыйфатламалары (мәйданы, күләме, озынлыгы, катлар саны, җитештерү куәте һ.б.));<br>мөрәҗәгать итүче – физик зат турында идентификация белешмәләре (фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен таныклаучы документның реквизитлары, төзүченең (техник заказчының) яшәгән урыны буенча адресы), юридик затның тулысынча аталышы, төзүче (техник заказчы) – юридик затның урнашкан урыны, ә төзүче (техник заказчы) һәм мөрәҗәгать итүче бер үк зат булмаган очракта, – шулай ук мөрәҗәгать итүчегә карата да күрсәтелгән белешмәләр);<br>капиталь төзелеш объектының смета яисә күздә тотылган (чик) бәясе турында федераль максатчан программа, региональ (муниципаль) программа раслау турында, яки дәүләт (муниципаль) мөлкәт объектларына бюджет инвестицияләре әзерләү һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | тормышка ашыру турында, яки дәүләт (муниципаль) мөлкәт объектларына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидия бирү турында, яки дәүләт корпорацияләренә (компанияләренә), гавами-хокук компанияләренә, шул исәптән мөлкәти кертем рәвешендә, дәүләт корпорацияләре (компанияләре), гавами-хокук компанияләре мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектларына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен, яки акцияләре (өлешләре) күрсәтелгән дәүләт корпорацияләренеке (компанияләренеке), гавами-хокук компанияләренеке булган юридик затларның устав (җыелма) капиталына мондый юридик затлар мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектларына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен кертем бирү, яки мондый юридик затларның бүлендек җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларына күрсәтелгән бүлендек җәмгыятьләре мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектларына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен алга таба кертем бирү максатларында  субсидияләр бирү турында, яки акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты Россия Федерациясенеке булган юридик затларга күрсәтелгән юридик затлар мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектларына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү турында, яки Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дәүләти яисә муниципаль учреждениеләр һәм дәүләти яисә муниципаль унитар предприятиеләр булып тормаган юридик затларга күрсәтелгән юридик затлар мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектларына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен яки күрсәтелгән юридик затларның бүлендек җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларына күрсәтелгән бүлендек җәмгыятьләре мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектларына яисә бюджет законнарында билгеләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | тәртиптә кабул ителгән федераль максатчан программалар, региональ (муниципаль) программалар составында чараларны (эреләндерелгән инвестиция проектларын) җентекләгәндә капиталь төзелеш объектларына карата капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен кертем бирү максатларында бюджет инвестицияләре бирү турында карарда бәян ителгән белешмәләр;<br><br>б) капиталь төзелеш объектына карата федераль мөлкәт объектларына карата федераль бюджет акчасын төп бүлүче, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт мөлкәте объектларына карата Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасын төп бүлүче яисә муниципаль мөлкәт объектларына карата җирле бюджет акчасын төп бүлүче җитәкчесе тарафыннан килештерелгән проект документациясе. Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затларның, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затларның төзелеше Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын җәлеп итмичә гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларына карата проект документациясе мондый юридик затның җитәкчесе тарафыннан килештерелә. Дәүләти яисә муниципаль учреждениеләр, дәүләти яисә муниципаль унитар предприятиеләр булып тормаган юридик затларның төзелеше Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларына карата проект документациясе мондый юридик затның җитәкчесе тарафыннан килештерелә. | |

| | |
|---|---|
| | Әгәр смета бәясен тикшерү бер үк вакытта проект документациясенә һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздырып башкарылса, смета бәясенә тикшерү уздыру турында гариза бер үк вакытта проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыру турында гариза белән тапшырыла, бу вакытта проект документациясе кабат тапшырылмый;<br>в) смета исәпләмәләрендә исәпкә алынган эшләрнең күләмнәре исемлекләре;<br>г) проектлау биреме;<br>д) инженерия эзләнүләрен башкару биреме (смета бәясенә тикшерү белән бер үк вакытта, проект документациясен әзерләү өчен башкарылган инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздыргач, проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыру очракларыннан тыш);<br>е) инженерия эзләнүләре нәтиҗәләре (смета бәясенә тикшерү белән бер үк вакытта, проект документациясен әзерләү өчен башкарылган инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздыргач, проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыру очракларыннан тыш);<br>ж) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә проект документациясе дәүләт экспертизасына тиешле булган очракта – проект документациясенә һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе (әгәр смета бәясенә тикшерү уздыру оешмасы белән проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздырган орган (оешма) бер үк булмаса);<br>з) мөрәҗәгать итүченең төзүче (техник заказчы) исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен раслаучы һәм аларның смета бәясенә тикшерү уздыру турында килешү (алга таба – килешү) төзү, үзгәртү, башкару, |

| | |
|---|---|
| | таркату вәкаләтләре махсус сөйләшенә торган документлар (әгәр мөрәҗәгать итүче төзүче (техник заказчы) булып тормаса);<br>и) Россия Федерациясенең дәүләт мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектларына карата – капиталь төзелеш объекты буенча карар (Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый акты яисә федераль бюджет акчасын төп бүлүченең бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм тормышка ашыру турында, капиталь төзелеш объектына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү турында карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль максатчан программа раслау турында норматив хокукый акты);<br><br>дәүләти яки муниципаль учреждениеләр һәм дәүләти яки муниципаль унитар предприятиеләр булып тормаган юридик затларның, төзелеше Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын җәлеп итеп фининанслана торган дәүләт компанияләрен һәм корпорацияләрен дә кертеп, капиталь төзелеш объектларына карата, – капиталь төзелеш объекты буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пунктының икенче абзацы, 78.3 статьясының 2 пункты яки 80 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә кабул ителгән һәм капиталь төзелеш объекты турында, шул исәптән аның смета яки күздә тотылган (чик) бәясе һәм куәте турында, мәгълүматларны үз эченә алган карар (Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең иң югары органы, җирле үзидарә органы норматив хокукый акты);<br>Россия Федерациясе субъектларының дәүләт мөлкәтендәге һәм (яисә) муниципаль мөлкәттәге капиталь төзелеш объектларына, шул исәптән |

| | |
|---|---|
| | төзелеше федераль бюджет акчасын җәлеп итеп финанслана торган объектларга карата, – капиталь төзелеш объекты буенча карар (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт мөлкәтендәге яисә муниципаль мөлкәттәге капиталь төзелеш объектларына, туры китереп, бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм тормышка ашыру турында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карар);<br>төзелеше дәүләт компанияләре һәм корпорацияләр акчасын җәлеп итеп (Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан акча җәлеп итмичә) финанслана торган капиталь төзелеш объектларына карата, – мондый юридик зат җитәкчесенең карары;<br>федераль максатчан программалар составында чараларны (эреләндерелгән инвестиция проектларын) җентекләгәндә – капиталь төзелеш объекты буенча карар (тиешле федераль максатчан программада билгеләнгән тәртиптә чараларны (эреләндерелгән инвестиция проектларын) җентекләү тәртибен билгеләүче методика буенча кабул ителгән һәм чарага (эреләндерелгән инвестиция проектына) керүче капиталь төзелеш объекты турында, шул исәптән аның смета яисә күздә тотылган смета (чик дәрәҗә) бәясе һәм куәте турында мәгълүматларны үз эченә алучы карар);<br><br>к) шушы пунктның «и» пунктчасында күрсәтелгән карарлар (актлар) булмаган очракта, шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау буенча проект документациясендә күрсәтелгән смета бәясе капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән смета яисә күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясеннән артып киткән очракта, – федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең, Россия Федерациясе |

| | |
|---|---|
| | тарафыннан төзелгән юридик зат җитәкчесенең, устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең, – бюджет планлаштыру субъектының (төзелешен федераль бюджет акчасы, күрсәтелгән юридик затлар акчасы хисабыннан финанслау планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесенең), җирле хакимият башлыгының, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан төзелгән юридик зат җитәкчесенең, устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (төзелешен финанслау Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчасы, күрсәтелгән юридик затлар акчасы хисабыннан гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә дәүләт компаниясенең, корпорациянең җитәкчесенең (капиталь төзелеш объекты Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан акча җәлеп итмичә, дәүләт компаниясе, корпорация акчасы хисабыннан төзелгән очракта) гаризада күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының смета яисә күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен раслаучы, капиталь төзелеш объектын төзүне финанслауның күздә тотылган, бюджет турында законда (карарда) каралган чыганаклары яисә бюджетныкы булмаган чыганаклар турында мәгълүматларны үз эченә алган хаты;<br>л) капиталь төзелеш объектын төзүдә аерым этапка карата проект документациясе әзерләгән очракта – тиешле федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (Россия Федерациясе субъекты дәүләт |

| | |
|---|---|
| | хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесенең) – тиешле бюджет акчасын төп юлучененең капиталь төзелеш объектын этаплап төзүне гамәлгә ашыру турында, капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның һәм аның куәтенең смета бәясен төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тотучы һәм барлык этаплар буенча объект төзелешенең гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми куәтен саклаганда объектны төзү буенча билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне артып китмәвен раслаучы карары (акты), яисә дәүләт компаниясенең, корпорациянең капиталь төзелеш объектын төзүдәге аерым этапка карата проект документациясе әзерләгән очракта, – дәүләт компаниясе, корпорация җитәкчесенең күрсәтелгән карары (акты). Мондый карарның күчермәсе (РФ Нигезләмәсенең 4 пунктындагы «б» һәм «б(2)» пунктчаларында күрсәтелгән объектларга карата карардан тыш) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрелә.<br><br>1.1. Үзләренә карата проект документациясе әзерләү таләп ителми торган һәм мондый документация төзүченең инициативасы белән эшләнмәгән капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясенә тикшерү уздырганда мөрәҗәгать итүче Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә шушы Регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчасының «а», «в», «з» - «л» өлешләрендә күрсәтелгән документларны, шулай ук федераль мөлкәт объектларына карата федераль бюджет акчасын төп бүлүче, Россия Федерациясе субъектының дәүләт мөлкәтендәге объектларга карата Россия Федерациясе |

субъекты бюджеты акчасын төп бүлүченең, муниципаль мөлкәттәге объектка карата җирле бюджет акчасын төп бүлүче җитәкчесе, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан төзелгән юридик затның, устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектының, мунципаль берәмлекнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затның җитәкчесе тарафыннан мондый юридик затның төзелеше, үзгәртеп корылышы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын җәлеп итмичә гамәлгә ашырыла торган объектларына карата, яисә дәүләти яки муниципаль учреждение, дәүләти яисә муниципаль унитар предприятие булып тормаган юридик зат җитәкчесе тарафыннан мондый юридик затның төзелеше, үзгәртеп корылышы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын җәлеп итеп финанаслана торган объектларына карата килештерелгән төзү, үзгәртеп кору бәясенең җыелма смета исәпләмәсен тапшыра.

1.2. Капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау буенча смета бәясенә тикшерү уздыру өчен, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын капиталь ремонтлаудан тыш, түбәндәгеләр тапшырыла:

а) әлеге Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасындагы «а», «в», «з» - «л» пунктчаларында күрсәтелгән документлар;

б) тиешле капиталь төзелеш объектларына карата, әлеге Регламентның 1.1.3 пунктчасында күрсәтелгән затлар тарафыннан капиталь ремонтлауның күздә тотылган (чик) бәясен билгеләү предметы буенча килештерелгән капиталь ремонт сметасы;

в) капиталь төзелеш объектын техник карау акты

| | |
|---|---|
| | (капиталь төзелеш объектын тикшерү нәтиҗәләре, мондый объектның төзелеш конструкцияләренең һәм инженерия җайланмаларының техник торышы һәм тикшерү датасына капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлау буенча эшләр составын, күләмен һәм чорларын билгеләү өчен төзелеш конструкцияләренең һәм инженерния җайланмаларының фактик сыйфат күрсәткечләренең санлы билгесе турында белешмәләрне үз эченә алган документ);<br><br>г) җитешсезлекләр исемлеге (капиталь төзелеш объектының техник торышын тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең бухгалтерлык исәбе турындагы законнары таләпләре нигезендә әзерләнгән һәм, мондый җитешсезлекләрнең сыйфатлы һәм санлы сыйфатламаларын күрсәтеп, төзелеш конструкцияләренең һәм инженерия җайланмасының җитешсезлекләр исемлеген үз эченә алган, беренчел исәпкә алу документы);<br>д) төзүченең яисә техник заказчының биреме нигезендә смета документациясеннән гайре проект документациясенең бүтән бүлекләрен әзерләү гамәлгә ашырылган очракта, әлеге пунктчаның «а»-»г» пунктчаларында күрсәтелгән документларга өстәмә, – проект документациясенең бүтән бүлекләре.<br>1.3. Мәдәни мирас объектларын саклау буенча мондый объектларның конструктив һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгы буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләрнең смета бәясенә тикшерү уздыру өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>а) әлеге Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасындагы «а», «в», «з» - «к» пунктчаларында күрсәтелгән документлар;<br>б) мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр |

| | |
|---|---|
| | башкаруга тиешле объектларга карата, әлеге Регламентның 1.1.3 пунктчасында күрсәтелгән затлар тарафыннан мондый эшләрнең күздә тотылган (чик) бәясен билгеләү өлешендә килештерелгән смета;<br>в) мәдәни мирас объектын техник карау акты (объектны тикшерү нәтиҗәләре, объектның төзелеш конструкцияләренең һәм инженерия җайланмаларының техник торышы һәм тикшерү датасына мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр составын, күләмен һәм чорларын билгеләү өчен төзелеш конструкцияләренең һәм инженерния җайланмаларының фактик сыйфат күрсәткечләренең санлы билгесе турында белешмәләрне үз эченә алган документ);<br><br>г) җитешсезлекләр исемлеге (мәдәни мирас объектының техник торышын тикшерү нәтиҗәләре буенча бухгалтерлык исәбе турында Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә әзерләнгән һәм, мондый җитешсезлекләрнең сыйфатлы һәм санлы сыйфатламаларын күрсәтеп, төзелеш конструкцияләренең һәм инженерия җайланмасының җитешсезлекләр исемлеген үз эченә алган, беренчел исәпкә алу документы);<br>д) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын яки ачыкланган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздыруга проект документацясе килештерү турында «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» Федераль закон нигезендә мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан бирелгән документ;<br>е) мәдәни мирас объектын саклау буенча аларны уздырганда мәдәни мирас объектының терәк булып |

| | |
|---|---|
| | торучы төзелеш конструкцияләрен алмаштыру һәм (яисә) торгызу күздә тотылган эшләрнең смета бәясенә тикшерү уздырылган очракта, мондый конструкцияләрнең аерым элементларын аналогик яки мондый элемент конструкцияләренең күрсәткечләрен яхшырта торганга алмаштыру һәм (яисә) күрсәтелгән элементларны торгызудан тыш, – әлеге Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасының «а»-»к» пунктчаларында һәм әлеге пунктчаның «д» пунктчасында күрсәтелгән документлар;<br>ж) мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрнең аерым этабына карата проект документациясе әзерләнгән очракта – тиешле федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесенең) – тиешле бюджеттан акчаларны баш бүлүченең мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрне гамәлгә ашыру турында мәдәни мирас объектын һәм аның куәтләрен саклау буенча эшләрнең смета бәясен эшләр этапларына бүлүне күздә тоткан һәм барлык этаплар буенча мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрнең гомуми смета бәясенең мәдәни мирас объектын саклау буенча билгеләнгән күздә тотылган (чик) бәядән артып китмәвен раслаучы карары (акты), яки мәдәни мирас объектын саклау буенча финанслануы дәүләт компаниясе, корпорациясе акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган эшләрнең аерым этабына карата проект документациясе әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе, корпорациясе җитәкчесенең күрсәтелгән карары (акты).<br><br>2. Проект документациясе әзерләү өчен башкарылган инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздырылганнан соң проект документациясенә дәүләт экспертизасы уздыру белән |

| | |
|---|---|
| | бер үк вакытта смета бәясенә тикшерү уздыру өчен әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчасында каралган документлар һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе тапшырыла. Бу вакытта инженерия эзләнүләрен башкару биреме һәм инженерия эзләнүләре нәтиҗәләре тапшырылмый.<br>3. Проект документациясенә дәүләт экспертизасы уздырылганнан соң смета бәясенә тикшерү уздыру өчен әлеге Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасындагы «а»-»г», «ж»-»к» пунктчаларында каралган документлар тапшырыла. Бу вакытта смета бәясен тикшерү өчен тапшырыла торган проект документациясе бүлекләренең составы һәм эчтәлеге килешүдә билгеләнә.<br>4. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе мөрәҗәгать итүчегә смета документациясендә каралган, аларны хисаплау өчен смета нормалары билгеләнмәгән чыгымнарга өстәмә исәпләмә нигезләүләр, яисә проект документларында каралган конструктив, технологик һәм башка чишелешләрне, шулай ук смета документациясенә кертелгән чыгымнарны күздә тотучы эшләрне башкару кирәклеген раслаучы инженерия эзләнүләре материалларын тапшыру зарурлыгы турында нигезле язмача гарызнамә җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән нигезләүләр һәм материаллар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле гарызнамә алынган датадан соң 10 көнлек чорда тапшырыла. Мөрәҗәгать итүчеләрдән бүтән белешмәләрне һәм документларны тапшыруны таләп итү рөхсәт ителми.<br>5. Проект документациясенең 11 яисә 9 бүлекләре төзелгәннән соң смета нормативлары һәм (яисә) смета бәясе исәпләмәләрен гамәлгә ашырганда исәпкә алынган төзелеш ресурсларының смета бәяләре |

| | | |
|---|---|---|
| | үзгәргән очракта, смета документациясе аны тикшерү уздыру өчен тапшыру датасына барлыкка килгән бәяләрне исәпкә алып, әлеге документациягә үзгәрешләр кертелгәннән соң смета бәясенә тикшерү уздыру өчен тапшырыла.<br>6. Әгәр капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь ремонты, мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләрне башкару аерым этапларга бүлеп гамәлгә ашырылса, смета бәясен тикшерү төзелешнең аерым этабына карата уздырылырга мөмкин. Бу очракта әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчаның «б» һәм «ж» өлешләрендә күрсәтелгән документлар төзелеш этапларына карата тапшырыла.<br>Смета бәясенә тикшерү уздыру өчен документлар электрон документлар рәвешендә тапшырыла, ә документларда дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булганда, – кәгазьдә.<br>Смета бәясен тикшерү өчен документлар кәгазьдә тапшырылшган очракта аларның форматы килешүдә билгеләнә. Бу вакытта аерым документлар, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә рөхсәт ителсә, шулай ук электрон документлар рәвешендә дә тапшырыла ала. Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче «ТР Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше «ТР Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенең рәсми сайтында урнаштырылган. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан соратыла торган документлар исемлеге:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән).<br>2. Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән).<br>3. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәвенә алу, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәт идарәсеннән).<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылган документлар асылы буенча каралмыйча мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелергә тиеш, – түбәндәге нигезләр буенча:<br>а) капиталь төзелеш объектының смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавын тикшерү бүтән орган яисә бүтән оешма тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиешле булса;<br>б) проект документациясе проект документациясенең эчтәлегенә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән составка һәм таләпләргә җавап бирмәгәндә, шул исәптән, әгәр проект документациясенең 9 яки 11 бүлеген төзегәннән соң төзелешнең смета бәясен исәпләгәндә исәпкә алынган смета нормативлары һәм (яки) төзелеш ресурсларының смета бәяләре үзгәрсә, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен смета документациясе, тикшерү уздыру өчен аны тапшыру датасына барлыкка килгән бәяләрне исәпкә алып, әлеге документациягә төзәтмәләр керткәннән соң тапшырыла;<br>в) шушы Регламентның 2.5 пунктында каралган барлык документлар да тапшырылмаганда яисә документларны шушы Регламентның 2.5, 2.16 пунктларында билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырганда. Бу вакытта кәгазьдә тапшырылган документлар Мөрәҗәгать итүчегә хәбәрләмә белән бергә кайтарып бирелергә тиеш. Электрон документлар рәвешендә тапшырылган документлар кайтарылмый һәм өч ай дәвамында Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсендә сакланырга тиеш. | РФ Нигезләм |
| 2.9. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәтен туктатып тору яисә аны | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр законнарда каралмаган. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Смета бәясенә тикшерү уздырган өчен түбәндәге күләмдә түләү алына:<br>а) 20 мең сум – түбәндәгеләрнең смета бәясенә тикшерү уздырылган очракта:<br>капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору;<br>мәдәни мирас объектын саклау буенча аларны уздырганда мәдәни мирас объектының терәк булып торучы төзелеш конструкцияләрен алмаштыру һәм (яисә) торгызу күздә тотылган эшләр, мондый конструкцияләрнең аерым элементларын аналогик яки мондый элемент конструкцияләренең күрсәткечләрен яхшырта торганга алмаштыру һәм (яисә) күрсәтелгән элементларны торгызудан тыш;<br>гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын капиталь ремонтлау;<br>смета бәясе 10 миллион сум һәм шуннан югары булган капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау (гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан тыш);<br>б) 20 мең сум – түбәндәгеләрнең смета бәясенә тикшерү уздырылган очракта:<br>смета бәясе 10 миллион сумга кадәр булган капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлау (гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан тыш);<br>әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелмәгән мәдәни мирас объектларын саклау эшләре.<br>Смета бәсенә кабатлап уздырыла торган тикшерү | РФ Нигезләм |

| | | |
|---|---|---|
| | өчен смета бәясенә уздырылган беренчел тикшерү өчен түләү күләменең 30 проценты күләмендә түләү алына.<br>Смета бәясен тикшерү мөрәҗәгать итүче акчасы хисабына гамәлгә ашырыла.<br>Смета бәясен тикшерү буенча хезмәтләргә түләү смета бәясен тикшерү нәтиҗәсендә бәйсез рәвештә гамәлгә ашырыла.<br>Түләү реквизитлары:<br>«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе<br>Юридик адрес: 420073, Казан шәһәре, Шуртыгин ур., 22<br>Почта адресы: 420054, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 125.<br>ИНН 1654017928/КПП 166001001<br>Казан ш. «Ак Барс» ГАҖ<br>Алучы: ТР Финанс министрлыгы Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе<br>л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен)<br>исәп счеты 40601810700023000003<br>БИК 049205805<br>К/с 30101810000000000805 | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризасын, шул исәптән электрон рәвештә дә, теркәү вакыты | Мөмкин булган иң күп чоры: мөрәҗәгать итүчедән гарызнамә алынганнан соң эш көне дәвамында.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм | Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: | Татарстан Ре<br>Кабинетының 880 |

| | | |
|---|---|---|
| сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе биналарының җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, рәсми сайтында, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) тулы мәгълүмат булу.<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгечләре тарафыннан шушы Регламент бозылуларга прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгечләре белән мөрәҗәгать итүченең хезмәттәшлек итүе саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле | тәртипнең 2.4 пунк<br>601 номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| | документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә бер мәртәбәдән артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең бүлек белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, рәсми сайтында, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) тулы мәгълүмат булу. | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон рәвештә күрсәтелә.<br>Смета бәясенә тикшерү уздыру өчен документлар электрон документлар рәвешендә тапшырыла, ә документларда дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булганда, – кәгазьдә.<br>Смета бәясен тикшерү өчен документлар электрон документлар рәвешендә, шул исәптән «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, тапшырылган очракта түбәндәге шартлар үтәлә:<br>электрон документлар Россия Федерациясе законнары нигезендә аларга имза салу вәкаләтләренә ия булган затлар тарафыннан «Электрон имза | 63-ФЗ номер<br>210-ФЗ номер<br>РФ Нигезләм<br>Россия Төзел<br>12 маендагы 783/п |

| | | |
|---|---|---|
| | турында» Федераль законда каралган көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзалана;<br>электрон документларның форматы Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы раслый торган таләпләргә җавап бирергә тиеш.<br>Смета бәясен тикшерү өчен документлар кәгазьдә тапшырылшган очракта аларның форматы килешүдә билгеләнә. Бу вакытта аерым документлар, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә рөхсәт ителсә, шулай ук электрон документлар рәвешендә дә тапшырыла ала.<br>Смета бәясен тикшерү өчен документларны электрон документлар рәвешендә тапшырган очракта, бәяләмә мөрәҗәгать итүчегә электрон документ рәвешендә җибәрелә, ә кәгазь документлар рәвешендә тапшырылган очракта, – кәгазь документ рәвешендә.<br>Кәгазь документ рәвешендә бәяләмә бирү (җибәрү) тәртибе, шулай ук кәгазь документ рәвешендә тапшырылган документларны кайтарып бирү тәртибе һәм вакыты килешүдә билгеләнә.<br>Килешүдә каралган очракларда мөрәҗәгать итүчегә электрон документ рәвешендәге бәяләмәдән тыш шулай ук кәгазь документ рәвешендә бәяләмә дә бирелергә (җибәрелергә) мөмкин.<br>Кәгазь документ рәвешендәге уңай бәяләмә 4 нөсхәдә бирелә (җибәрелә), тискәресе, – бер нөсхәдә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Мөрәҗәгать итүченең шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар җыелмасы белән Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә мөрәҗәгать итүе дәүләт хезмәтен күрсәтә башлау өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылган документларны тикшерү;

4. Электрон рәвештә белешмәләр бирү турындагы гарызнамәләрне ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) ярдәмендә җибәрү һәм соралучы документларны (белешмәләрне) алу;

5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү бәясен ачыклау һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен килешү проекты җибәрү;

6. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белән мөрәҗәгать итүче арасында дәүләт хезмәте күрсәтүгә килешү төзү йә, мөрәҗәгать итүче булып – дәүләт казна учреждениесе, ә түләүче булып бүтән зат катнашкан очракта, «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ, мөрәҗәгать итүче һәм түләүче арасында капиталь төзелеш объектларының смета бәясен дөрес итеп билгеләүне тикшерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә килешү төзү;

7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү;

8. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәләре һәм мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең блок-схемасы шушы Регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгече Мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгече мөрәҗәгать итүчене дәүләт хезмәтен алу предметы буенча консультацияли, һәм зарурлык булганда гариза тутыруда ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла, электрон почта аша мөрәҗәгать иткәндә, – мөрәҗәгатьне теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча консультацияләр.

3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәүгә алу.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза һәм шушы Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документлар тапшыра.

Смета бәясенә тикшерү уздыру өчен документлар электрон документлар рәвешендә тапшырыла, ә документларда дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булганда, – кәгазьдә.

Электрон рәвештә тапшырылган гариза номер һәм теркәүгә алу датасын теркәү юлы белән теркәүгә алына.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гариза тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гаризаны теркәүгә алу.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылган документларны тикшерү.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе документацияне кабул итү белән шөгыльләнүче белгечләре кирәкле документларның булу-булмавын, аларның (рәвеше, эчтәлеге буенча, вакытлары һәм рәсмиләштерелүе буенча) билгеләнгән таләпләргә җавап бирү-бирмәвен тикшерә:

документларның текстлары аңлаешлы, юридик затларның аталышы – кыскартылмыйча, аларның урнашкан урыннарын күрсәтеп язылган булырга тиеә;

физик затларның фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, аларның яшәгән урын адреслары тулысынча язылган булырга тиеш;

документларда чистартылган, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм алдан сөйләшенмәгән бүтән төзәтмәләр булырга тиеш түгел;

кирәкле барлык документларның составы һәм эчтәлеге шушы Регламент һәм Россия Федерациясе законнары таләпләренә җавап бирергә тиеш.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгечләре өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүчедән өстәмә рәвештә аларны хисаплау өчен смета нормалары билгеләнмәгән сарыфларның смета документациясендә каралган исәп-хисап нигезләүләрен, яисә проект документациясендә каралган конструктив, технологик һәм башка карарларны, шулай ук эшләр башкару зарурлыгын раслый торган, чыгымнары смета документациясенә кертелгән инженерия эзләнүләре материалларын соратып алырга хокуклы. Күрсәтелгән нигезләүләр һәм материаллар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле гарызнамә алынган датадан соң 10 көнлек чорда тапшырыла. Мөрәҗәгать итүчеләрдән бүтән белешмәләрне һәм документларны тапшыруны таләп итү рөхсәт ителми.

Әгәр мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда документларның асылы буенча каралмаска тиешлеген тануга нигез булып торучы, ләкин бетереп була

торган җитешсезлекләр ачыкланса, документация кабул итү бүлеге хезмәткәре документларның тулы булмавы турында хат җибәрә һәм мондый җитешсезлекләрне бетерү өчен 30 эш көненнән артмаган чор билгели.

Документлар җыелмасы (җитешсезлекләрне бетергәннән соң) законнардагы таләпләргә җавап биргән очракта, теркәлгән гариза дәүләт хезмәте бәясен ачыклау өчен җаваплы хезмәткәргә тапшырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза килгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаризаны бәя ачыклау өчен тапшыру, яисә мөрәҗәгать итүчегә документларның тулы булмавы турында хат җибәрү.

3.5. ВЭМХ системасы ярдәмендә электрон рәвештә белешмәләр бирү турында гарызнамәләр җибәрү һәм сорала торган документларны (белешмәләрне) алу.

3.5.1. Техник хезмәт белгече Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә түбәндәгечә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм юридик реестрыннан белешмәләр бирү турында;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр бирү турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре шушы Регламентның 3.5.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән гарызнамәләр нигезендә соралучы белешмәләрне (документларны) билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә җибәрелгән, гарызнамәләргә җавап нәтиҗәсе булып торучы белешмәләр (документлар), яисә аларны бирүдән баш тарту турында хәбәрләмә.

3.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү бәясен ачыклау һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен килешү проектын җибәрү.

3.6.1. Техник хезмәт белгече шушы Регламентның 2.9 пункты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча түләү күләменә исәпләмә әзерли.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча түләүнең рәсми исәпләмәсе килешү проектын әзерләү өчен җаваплы булган бүлек хезмәткәренә җибәрелә.

Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүгә килешү проекты әзерли, мондый килешүгә номер суга, датасын терки, аны дәүләт хезмәте күрсәтүгә килешүләр реестрында теркәүгә ала.

Теркәүгә алынган килешү проекты дәүләт хезмәтенә түләү өчен счет формалаштыру буенча бухгалтерлык исәбе бүлегенә тапшырыла.

Бухгалтерлык исәбе бүлегенең җаваплы белгече дәүләт хезмәте өчен түләүгә счет язып бирә. Рәсмиләштерелгән килешү проекты һәм дәүләт хезмәте өчен түләү счеты имза кую өчен бухгалтер тарафыннан Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгына яисә вәкаләтле затка тапшырыла.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгы тарафыннан имзаланган килешү проекты һәм счет техник хезмәтнең җаваплы белгеченә тапшырыла. Бүлек белгече кул кую өчен килешү проекты һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә түләү өчен счет нөсхәләрен мөрәҗәгать итүчегә (яки, әлеге Регламентта каралган очракларда, мөрәҗәгать итүчегә һәм түләүчегә) тапшыра (почта аша җибәрә). Мөрәҗәгать итүче (яисә әлеге Регламентта каралган очракларда, мөрәҗәгать итүче һәм түләүче) килешү проектын кулга алганда килешүләр бирү журналындагы дата билгесе белән үз имзасын куя.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (яки, әлеге Регламентта каралган очракларда, мөрәҗәгать итүчегә һәм түләүчегә) исәп-хисап белән килешү проектын һәм түләү өчен счет тапшыру (җибәрү).

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм документация алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.7. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белән мөрәҗәгать итүче арасында (йә, әлеге Регламентта каралган очракларда, мөрәҗәгать итүче һәм түләүче арасында) дәүләт хезмәте күрсәтүне башкаруга килешү төзү.

Мөрәҗәгать итүчедән (яисә, әлеге Регламентта каралган очракларда, түләүчедән) «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенең исәп-хисап счетына дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кучкәннән соң, мөрәҗәгать итүче тарафыннан (яисә, әлеге Регламентта каралган очракларда, мөрәҗәгать итүче һәм түләүче тарафыннан) тиешенчә рәсмиләштергән килешүнең бер нөсхәсе кире кайтарылганнан соң проектларны алып бару бүлеге белгече экспертка карау өчен документларны карау мөмкинлеген ача.

Процедураларның нәтиҗәсе: документацияне карауга тапшыру.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түләү күчкән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү.

Эксперт-башкаручы документациягә анализ ясый һәм смета нормативларының федераль реестрына кертелгән смета нормативларына, проект документациясендә каралган эшләрнең физик күләменә, конструктив, оештыру-технологик һәм башка карарларга туры килү-килмәвен билгеләү максатларында смета документациясендә булган исәпләмәләрне бәяли.

Конструктив карар бәясе нормативын смета нормативларының федераль реестрына кертү өчен смета документациясендәге исәпләмәләрне бәяләү аларның смета нормативларының федераль реестрына кертелгән бүтән смета нормативларына (шул исәптән элеметнлы смета нормаларына) туры килү-килмәвен билгеләү максатларында гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә смета документациясенә үзгәрешләр кертү килешүдә каралган чорларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Әгәр дәүләт хезмәтен күрсәткәндә тапшырылган исәпләмәләрнең төгәл яисә төгәл булмавы турында йомгак ясарга мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (белешмәләрнең, тасвирламаларның, исәпләмәләрнең, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы яисә тулы булмавы) ачыкланса, өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә

ачыкланган җитешсезлекләр турында хәбәрләмә җибәрелә һәм, зарурлык булганда, аларны бетерү чоры билгеләнә. Эксперт-башкаручы кисәтүләренә җавап һәр кисәтү пункты буенча язмача рәвештә әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә тапшырылырга тиеш, шулай ук электрон рәвештә төзәтелгән смета документациясе дә тапшырыла.

Эксперт-башкаручы смета бәясен ачыклауның төгәл яисә төгәл булмавына карата нәтиҗә ясый һәм моның өчен шәхсән җаваплы була, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләренә карап, бәяләмә уңай (төгәл булуы турында) яисә тискәре (төгәл булмавы турында) булырга мөмкин.

Эксперт-башкаручы капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булмавы турында бәяләмә рәсмиләштерә, әгәр:

а) ачыкланган җитешсезлекләрне смета бәясен тикшерү процессында бетерүе мөмкин булмаса яки мөрәҗәгать итүче аларны билгеләнгән срокта бетермәсә;

б) смета документларындагы исәп-хисаплар расланган смета нормативларына туры килми, алар турында белешмәләр смета нормативларының федераль реестрына кертелгән;

в) смета документациясендә проект документациясендә кабул ителгән эшләрнең, конструктив, оештыру-технологик һәм башка чишелешләрнең исәпләмәләрдә кулланылган физик күләмнәренең дөрес һәм (яки) нигезле булмавына бәйле хаталар ачыкланса.

Эксперт-башкаручы бәяләмә әзерли, бәяләмәне вакытында рәсмиләштергән өчен җавап бирә, аны, алга таба рәсмиләштерүгә тапшыру өчен, бәяләмәләр бирү бүлеге белгеченә җибәрә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе эксперт-башкаручы тарафыннан Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 29 мартындагы 655/пр номерлы боерыгы нигезендәге рәвеш буенча бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: раслау өчен әзерләнгән бәяләмә проекты.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач егерме эш көне дәвамында башкарыла.

3.9. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәләре һәм мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү.

3.9.1. Бәяләмәләр бирү бүлеге белгече бәяләмәне раслау өчен Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгына яисә аның вәкаләтле затына җибәрә.

Процедуралар нәтиҗәсе: расланган бәяләмә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар эксперт-башкаручы тарафыннан бәяләмә проекты әзерләнгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.9.2. Бәяләмәләр бирү бүлеге белгече бәяләмәләрне теркәүгә алуны һәм бирүне гамәлгә ашыра.

Бәяләмә мөрәҗәгать итүчегә электрон документ рәвешендә җибәрелә, гаризада кәгазь рәвешендә бәяләмә бирү турында күрсәтелгән очракта, кәгазь документ рәвешендәге бәяләмә бирелә.

Килешүдә каралган очракларда мөрәҗәгать итүчегә электрон документ рәвешендәге бәяләмәдән тыш шулай ук кәгазь документ рәвешендә бәяләмә дә бирелергә (җибәрелергә) мөмкин.

Кәгазь документ рәвешендәге уңай бәяләмә дүрт нөсхәдә бирелә (җибәрелә), тискәресе, – бер нөсхәдә.

Бәяләмә белән берлектә мөрәҗәгать итүчегә кәгазь рәвешендә тапшырылган документация тапшырыла.

Бәяләмәне алу өчен Мөрәҗәгать итүче Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә шәхесен таныклаучы документны, Мөрәҗәгать итүченең вәкиле юридик затның законлы вәкиле тарафыннан таныкланган ышанычнамәне һәм шәхесен таныклаучы документны күрсәтергә тиеш.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар бәяләмә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгы тарафыннан расланган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә теркәлгән бәяләмәне бирү.

3.9.3. Бәяләмәне югалткан очракта мөрәҗәгать итүче аның дубликатын алу хокукына ия. Бәяләмә дубликаты, түләү алмыйча, мөрәҗәгать итүченең язмача рәвештәге мөрәҗәгате Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан алынганнан соң 10 көн дәвамында бирелә.

3.10. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.

3.11. Бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән бәяләмәдә җибәрелгән техник хаталарны бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла, анысы ирекле рәвештә (5 нче кушымтадагы үрнәктә), төзәтелергә тиешле хаталарны күрсәтеп тапшырыла. Гаризага дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган бәяләмәләрнең нөсхәләре һәм мөрәҗәгать итүченең техник заказчы (төзүче) исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен раслый торган документ теркәлә.

3.11.1. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм терки;

гариза Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгы тарафыннан каралганнан соң, башлык бәяләмәгә үзгәрешләр кертү яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап әзерләү турындагы резолюция имзалый, башкару өчен җаваплы белгеч билгели.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза алынган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән, башкару өчен җаваплы белгечкә тапшырылган гариза.

3.11.2. Җаваплы белгеч:

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгының бәяләмәгә үзгәрешләр кертү турында яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли;

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгының боерык проектын килештерү өчен Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгына (ул булмаганда аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бүлеккә җибәрелгән

вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директорына килештерү өчен юнәлдерелгән боерык проекты.

3.11.3. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе башлыгы (ул булмаганда – аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат) бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү турында яисә бәяләмәгә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерыкны раслый. Кул куелган боерык җаваплы белгечкә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура проектны раслауга алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү турында яисә бәяләмәгә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар.

Бәяләмәгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән очракта, белгеч мөрәҗәгать итүчегә, техник хатаны төзәтү турында гаризада яисә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, бәяләмәнең әзер булуы турында хәбәр итә һәм мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап:

әгәр дә мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе алу теләген белдергән булса, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне тапшыру датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар беренче бәяләмәгә үзгәрешләр кертелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән бәяләмәне алу ысулын килештерү.

Үзгәрешләр кертүдән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүчегә язмача җавап бирелә.

3.11.4. Мөрәҗәгать итүчегә техник хатасы төзәтелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру.

Җаваплы белгеч, мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап, бәяләмәне яисә бәяләмәгә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавапны тапшыра (җибәрә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүчедән җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән, техник хатасы төзәтелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан шушы Регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның үтәлүен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшереп тору эше тиешле административ процедураны башкару өчен җаваплы булган зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы тикшереп тору Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затларның шушы Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм

башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

4.4. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе актлары нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавына тикшерүләр уздырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

4.5.1. әлеге Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актларның таләпләре бозылуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

4.5.2. физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында үзләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе, шулай ук вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затларының (хезмәткәрләренең) гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе җитәкчесенә шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр хезмәт күрсәтелүгә бәйле рәвештә

Министрлыкка тапшырыла, дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яки монополиягә каршы органга бирелә.»;

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://minstroy.tatarstan.ru/), Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайты (http://gosekspertiza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең

(функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6 Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7.2. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта,

Мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

## ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны һәм документларны техник хезмәткә җибәрү

↓

Техник хезмәт белгече тарафыннан белешмәләр бирү турында ВЭХС аша гарызнамәләр җибәрү һәм электрон рәвештә җаваплар алу

↓

Техник хезмәт белгече документлар тупланмасының тулы булу-булмавын тикшерә

Тапшырылган документлар җыелмасын тулыландыру зарурлыгы турында хат

↓ ↓

Регламентка 1 нче кушымтада «Техник хезмәт белгече тарафыннан Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белән Мөрәҗәгать итүче арасында, дәүләт хезмәте күрсәтү бәясен билгеләп, хезмәт

күрсәтүгә килешү проектын әзерләү, килешүне Мөрәҗәгать итүчегә җибәрү» дигән юлында «(яисә, әлеге Регламентта каралган очракларда, мөрәҗәгать итүчегә һәм түләүчегә)» сүзләрен өстәргә;

↓

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең экспертиза хезмәте экспертлары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү

↓

Бәяләмәләр бирү бүлеге белгече тарафыннан уңай (тискәре) бәяләмәне теркәүгә алу һәм бирү

Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Үрнәк

Түләүле хезмәтләр күрсәтү килешүе

Казан шәһәре ______________________________

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе («ТР Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ), алга таба «Башкаручы» дип исемләнеп, ____________________________ нигезендә гамәл кылучы ________________ йөзендә, бер яктан, һәм ________________________ нигезендә гамәл кылучы ________________________ йөзендә, алга таба «Заказчы» дип исемләнеп, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип исемләнеп, әлеге килешүне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында:

1. Килешүнең предметы

1.1. Әлеге килешү шартлары буенча башкаручы заказчы гаризасы буенча капиталь төзелеш объектының смета бәясен дөрес итеп билгеләүне тикшерү үткәрергә тиеш: ______________________________ (алга таба – хезмәтләр, смета бәясен тикшерү), ә заказ бирүче хезмәтләрне кабул итәргә һәм түләргә тиеш.

1.2. Смета бәясенең билгеләүнең төгәл булуын тикшерү нәтиҗәсе булып

Башкаручының капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең дөрес булуы (уңай бәяләмә) яки дөрес булмавы (тискәре бәяләмә) турында бәяләмәсе тора.

1.3. Заказчы тикшерү уздыру өчен тапшырыла торган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 427 номерлы карары белән расланган Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан акчалар, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 4 пунктындагы «б (1)», «б (3)» пунктчаларында каралган документациянең капиталь төзелеш объектларына карата башкарылуын гарантияли һәм раслый.

## 2. Хезмәтләрнең бәясе һәм исәп-хисап ясау тәртибе

2.1. Хезмәтләрнең бәясе Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

2.2. Шушы Килешүнең 1.1 пункты нигезендә хезмәтләр күрсәтелгән өчен Түләүче Башкаручыга _________________ тәшкил итүче бәяне, шул исәптән 20% ставка буенча НДС - _____________ түли.

2.3. Хезмәтләр өчен түләү хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә башкарыла.

2.4. Заказчы шушы килешү имзаланган вакыттан башлап биш эш көне эчендә хезмәтләр бәясенең 100%ы күләмендә аванс түләү бурычын үз өстенә ала. Счет алдан түләү кертү нигезе булып тора. Башкаручы аванс суммасы килгән көннән башлап исәпләнә торган биш календарь көненнән соңга калмыйча Заказчыга күрсәтеләчәк хезмәтләр өчен счетка аванс түләве буенча счет-фактура бирә.

2.5. Счетны түләү көне булып акча чараларының Башкаручының исәп-хисап счетына килгән, банк өземтәсендә расланган көн санала.

2.6. Түләү Заказчының язмача күрсәтмәсе нигезендә акча чараларын өченче зат тарафыннан Башкаручының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән башкарылырга мөмкин.

## 3. Хезмәт күрсәтү чоры

3.1. Башкаручының исәп-хисап счетына шушы килешүнең 2 бүлегендә күрсәтелгән аванс күчерелгәннән соң, Башкаручы 23 эш көне эчендә смета бәясен тикшерә һәм бәяләмә әзерли.

Смета бәясен тикшерү вакыты Заказчының язмача мөрәҗәгате нигезендә иң

күбе 30 эш көненә озайтылырга мөмкин.

3.2. Башкаручы килешү мөнәсәбәтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән һәм Нигезләмә һәм шушы килешүнең 2.5 пункты нигезендә Заказчы тарафыннан алдын түләү кертелгән көннән соңгы көндә хезмәт күрсәтүгә керешә.

3.3. Хезмәтләрне күрсәтү Яклар тарафыннан имзаланган, Башкаручы тарафыннан раслана торган рәвештәге (шушы килешүгә 1 нче кушымта) Күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү акты (алга таба – Акт) белән раслана.

Әгәр дә Заказчы Актка кул куюдан баш тартса, ул вакытта ул Башкаручыга Актны алган һәм Башкаручы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән көннән соңгы биш календарь көне эчендә язмача баш тартуны тапшырырга бурычлы. Әгәр дә Заказчы тарафыннан Башкаручыга билгеләнгән вакытларда дәлилле баш тарту тапшырылмаса, Акт Заказчы тарафыннан имзаланган һәм хезмәт Башкаручы тарафыннан тулы күләмендә нинди дә булса ризасызлыкларсыз күрсәтелгән дип санала. Дәлилле баш тартуда әлеге килешүдә каралган бурычлар чиген уздырмый торган кисәтүләр булырга тиеш.

## 4. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Заказчының хокуклары:

4.1.1. Смета бәясен тикшерү барышы турында мәгълүмат алырга.

4.1.2. Башкаручыга Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып, электрон документлар рәвешендәге өстәмә документларны тапшыру.

Оператив рәвештә Башкаручы тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен проект документларына үзгәрешләр кертү.

4.2. Заказчының бурычлары:

4.2.1. Рәсмиләштерелгән килешүне имзалау һәм Башкаручыга кайтару, әлеге килешү нигезендә хезмәтләр күрсәтү өчен түләү.

Хезмәт күсрәтелүнең нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә, Акт буенча хезмәтне кабул итү, имзалау һәм уңай яисә тискәре бәяләмә рәсмиләштерелгән датадан соң биш календарь көне эчендә Башкаручыга Актны кайтарып бирү һәм счет-фактура алу.

4.2.2. Башкаручының сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яисә «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып электрон документлар рәвешендә, яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, – кәгазьдә составы һәм эчтәлеге буенча гамәлдәге норматив хокукый актларның таләпләренә җавап бирә торган, смета бәясен тикшерү өчен зарури документацияне Башкаручыга тапшыру.

Тапшырылган документларның сыйфатлы һәм төгәл булуы өчен Заказчы җаваплы була.

4.2.3. Башкаручыга тикшерү өчен кирәкле булган, составы һәм эчтәлеге буенча норматив хокукый актлардагы таләпләргә җавап бирүче смета документациясен, төзү һәм монтажлау эшләренең күләмнәре исемлекләрен, җайланма, җиһаз һәм инветарь буенча заказ спецификацияләрен һәм Нигезләмәдә каралган бүтән документларны тапшыру.

4.2.4. Башкаручы гарызнамәсе нигезендә аларны исәпләү өчен смета нормалары билгеләнмәгән, смета документациясендә каралган чыгымнар буенча өстәмә исәпләмә нигезләүләрен, яисә проект документациясендә каралган конструктив, технологик һәм башка карарларны, шулай ук чыгымнары смета документациясенә кертелгән эшләрне башкаруның кирәклеген раслаучы инженерия эзләнүләре материалларын мондый гарызнамәне алганнан соң 10 көн эчендә тапшыру.

4.2.5. Әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган тәртиптә смета документациясенә үзгәрешләр кертү, җитешсезлекләрне бетерү.

4.3. Башкаручының хокуклары:

4.3.1. Әлеге килешү шартлары нигезендә хезмәтләр өчен түләүне таләп итү.

4.3.2. Дәүләт хакимияте органнарыннан, аларга буйсынучы оешмалардан смета бәясен тикшерү һәм Башкаручыга йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен зарури материалларны сорату.

4.3.3. Заказчының ризалыгыннан башка смета бәясен тикшерү өчен бүтән дәүләти һәм (яисә) дәүләтнеке булмаган оешмаларны, шулай ук белгечләрне җәлеп итү.

